**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2026 елның 2 апреле** **34-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында»гы 77-РС нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2026 елның 20 февралендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 32 статьясы 2 өлешенең 29 пунктындагы «д» подпунктын үз көчен югалткан дип тану турында»гы 23-ФЗ нче номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 12 ноябрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 нче номерлы карарына үзгәреш кертү турында»гы 1783 нче номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында»гы 77-РС нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1.2 пунктының 1 абзацында «муниципаль торак фонды» дигән сүзләрне «аның милек формасына карамастан» дигән сүзләр белән алыштырырга. Әлеге үзгәреш 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә, ләкин ул рәсми рәвештә бастырып чыгарылган көннән соң бер ай узганнан да иртәрәк түгел.

2. 1.2 пунктының 9 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
– «ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортка турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашырганда күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтен карап тоту һәм (яисә) ремонтлау буенча эшләрне башкару яисә хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән затлар, күпфатирлы йорттагы биналарның мондый милекчеләре тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар тарафыннан

торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләрне».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Р.Г.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы –**
**Совет рәисе:** **И.Ф.Зарипов**